ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ТУКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
КҮЗКӘЙ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**КАРАР**

« 30» январь 2026 ел　　　　Күзкәй авылы　　　　№1

Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Күзкәй авылы җирлегендә җирләү буенча хезмәт күрсәтүнең гарантияләнгән исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләрнең бәясен раслау турында

«Җирләү һәм җирләү эше турында» 12.01.1996 ел, № 8-ФЗ Федераль законның 9 статьясындагы 3 өлеше, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 ел, № 131-ФЗ Федераль законның 16 статьясындагы 1 өлешенең 23 пункты, авыл җирлеге Уставы нигезендә,

**КАРАР БИРӘ:**

1. 2026 елның 1 февраленнән Тукай муниципаль районы Күзкәй авыл җирлегендә җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияләнгән исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләрнең бәясен 1 һәм 2 кушымталар нигезендә 9 678,63 сум күләмендә билгеләргә һәм гамәлгә кертергә.
2. Әлеге карарның гамәлдә булуын 01.02.2026 елдан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә җәелдерергә.
3. Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Күзкәй авыл җирлеге Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Күзкәй авыл җирлегендә җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияләнгән исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләрне раслау турында» 30.01.2025 №3 карарын үз көчен югалткан дип танырга.
4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районының рәсми сайтында «авыл җирлекләре» бүлегендә (tukay.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http//pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.
5. Әлеге карар үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Башкарма комитет Җитәкчесе　　　　Э.Р. Гәрәев

Тукай муниципаль районы Күзкәй авыл җирлеге Башкарма комитетының 2026 елның 30 январендагы 1 номерлы карарына 1 кушымта

2026 елның 1 февраленнән ТР Тукай муниципаль районы Күзкәй авыл җирлегендә җирләү буенча хезмәтләрнең бәясе

| **Хезмәт күрсәтү исеме** | **Хезмәт күрсәтү бәясе (сумнарда)** |
|---|---|
| 1. Җирләү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү | - |
| 2. Ритуаль билгеләнештәге предметларны бирү һәм китерү | 2275,00 |
| 3. Транспорт хезмәтләре күрсәтү (мәрхүмнең мәетен зиратка алып бару, ритуаль билгеләнештәге предметларны китерү) | 2370,00 |
| 4. Җирләү (кабер казу һәм күмү) | 5033,63 |
| **Барлыгы:** | 9678,63 |

Тукай муниципаль районы Күзкәй авыл җирлеге Башкарма комитетының 2026 елның 30 январендагы 1 номерлы карарына 2 кушымта

2026 елның 1 февраленнән ТР Тукай муниципаль районы Күзкәй авыл җирлегендә җирләү буенча хезмәтләрнең бәясе

| **Хезмәт күрсәтү исеме** | **Хезмәт күрсәтү бәясе (сумнарда)** |
|---|---|
| 1. Җирләү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү | - |
| 2. Мәетне кафенгә төрү | 385,00 |
| 3. Ритуаль билгеләнештәге предметларны бирү һәм китерү | 1890,00 |
| 4. Транспорт хезмәтләре күрсәтү (мәрхүмнең мәетен зиратка алып бару, ритуаль билгеләнештәге предметларны китерү) | 2370,00 |
| 5. Җирләү (кабер казу һәм күмү) | 5033,00 |
| **Барлыгы:** | 9678,63 |